# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Мамыш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“29” март 2024 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 29 мартында 12 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде:

Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Мамыш торак пунктында гражданнар Җыенының 15.11.2023 ел №2 карарына үзгәрешләр кертү, карарның 2 һәм 3 пунктларын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итү:

«2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган тубәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Мамыш авылы территориясендә агач һәм куакларны чистарту, кисү, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

3. 2022 елдагы экономияләнгән үзара салым акчасын түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзекәндерү, ремонтлау, карап тоту (Мамыш авылында урам юлларын ремонтлау өчен вак таш сатып алу)»

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 49 (кырык тугыз) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 27 (егерме җиде) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 27 (егерме җиде) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Мамыш авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2.“Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Мамыш торак пунктында гражданнар Җыенының 15.11.2023 ел №2 карарына үзгәрешләр кертү, карарның 2 һәм 3 пунктларын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итү” :

«2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Мамыш авылы территориясендә агач һәм куакларны чистарту, кисү, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

3. 2022 елдагы экономияләнгән үзара салым акчасын түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзекәндерү, ремонтлау, карап тоту (Мамыш авылында урам юлларын ремонтлау өчен вак таш сатып алу)» мәсьәләсе буенча карарны танырга.

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Мамыш авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.